**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«30» 06 2026 № 2157

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшә территорияләр чикләрен билгеләү турында

«Этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы һәм РФ Хөкүмәтенең «Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшә территорияләр чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2026 елның 10 апрелендәге 394 нмерлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районында 1 кушымта нигезендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләр исемлеген расларга һәм янәшә территорияләр чикләрен билгеләргә.

2. Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшә территорияләр чикләрен билгеләү механизмын 2 кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарны имзаланган көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Яр Чаллы территориаль органына җибәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Г.Ә. Галимовага йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

1 кушымта
Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның ______ ______________ ____ номерлы карары белән расланган

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА АЛКОГОЛЬ ПРОДУКЦИЯСЕН ВАКЛАП САТУ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ТУКЛАНУЫ ХЕЗМӘТЛӘРЕ КҮРСӘТКӘНДӘ АЛКОГОЛЬ ПРОДУКЦИЯСЕН ВАКЛАП САТУ РӨХСӘТ ИТЕЛМИ ТОРГАН КАЙБЕР ОЕШМАЛАРГА ҺӘМ ОБЪЕКТЛАРГА ЯНӘШӘ ТЕРРИТОРИЯЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

| тәртип № | Объект исеме | Стационар сәүдә объекты/җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүче объект | Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшә территорияләрнен размеры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Балалар мәгариф оешмалары | Стационар сәүдә объекты | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыныннан кимендә 45 метр зонада |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүче объект | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыныннан кимендә 45 метр зонада |
| 2 | Медицина оешмалары | Стационар сәүдә объекты | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыныннан кимендә 10 метр зонада |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүче объект | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыныннан кимендә 10 метр зонада |
| 3 | Спорт объектлары | Стационар сәүдә объекты | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыныннан кимендә 50 метр зонада |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүче объект | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыныннан кимендә 50 метр зонада |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Күпләп һәм ваклап сату базарлары | Стационар сәүдә объекты | Объектка керү урыннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыннан кимендә 50 метр зонада |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүче объект | Объектка керү урыннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыннан кимендә 50 метр зонада |
| 5 | Гражданнар күпләп җыела торган урыннар | Стационар сәүдә объекты | Объектка керү урыннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыннан кимендә 10 метр зонада |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүче объект | Объектка керү урыннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыннан кимендә 10 метр зонада |
| 6 | РФ субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән югары куркыныч чыганаклары | Стационар сәүдә объекты | Объектка керү урыннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыннан кимендә 50 метр зонада |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүче объект | Объектка керү урыннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыннан кимендә 50 метр зонада |
| 7 | Хәрби билгеләнештәге объектлар | Стационар сәүдә объекты | Объектка керү урыннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыннан кимендә 50 метр зонада |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүче объект | Объектка керү урыннан яки аерымланган территориягә (ул булганда) керү урыннан кимендә 50 метр зонада |

2 кушымта
Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның ____________ ____
номерлы карары белән расланган

# АЛКОГОЛЬ ПРОДУКЦИЯСЕН ВАКЛАП САТУ РӨХСӘТ ИТЕЛМИ ТОРГАН ЯНӘШӘ ТЕРРИТОРИЯЛӘР ЧИКЛӘРЕН БИЛГЕЛӘҮ МЕХАНИЗМЫ

1. Әлеге механизм Тукай муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшә территорияләр чикләрен билгеләүгә бертөрле якын килүне билгели.

Стационар сәүдә объекты – бинадан яки бинаның бер өлешеннән, корылмадан яки төзелешнең бер өлешеннән торган, мондый бинаның фундаменты белән нык бәйләнгән, җир белән төзелмәне тәшкил иткән һәм инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтырылган, алкоголь продукциясен ваклап сату гамәлгә ашырыла торган сәүдә объекты.

Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүче объект – җәмәгать туклануы продукциясен әзерләү, җәмәгать туклануы продукциясен һәм сатып алынган товарларны (шул исәптән сәнәгатьтә әзерләнгән азык-төлек продуктларын) әзерләү урынында да, заказлар буенча аннан читтә дә куллану һәм сату өчен шартлар тудыру өчен шулай ук төрле, шул исәптән кулланучыларның ялын оештыру буенча өстәмә хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән хуҗалык эшчәнлеге объекты.

2. Янәшә территория аерымланган территорияне (андый территория булганда), шулай ук җирлекнең һәм төзелешнең конкрет үзенчәлекләрен исәпкә алып билгеләнә торган, аерымланган территория чикләренә яисә турыдан-туры 1 кушымтада күрсәтелгән оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бинага (төзелешкә, корылмага) тоташып киткән территорияне (алга таба – өстәмә территория) үз эченә ала.

Өстәмә территория билгеләнә:

а) аерымланган территория булганда – аерымланган территориягә килүчеләр өчен керү урыныннан алып стационар сәүдә объектына яки җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүче объектка керүчеләр өчен керү урынына кадәр;

б) аерымланган территория булмаганда – 1 кушымтада күрсәтелгән оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бинага (төзелмәгә, корылмага) килүчеләр өчен керү урыныннан алып стационар сәүдә объектына яки җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүче объектка килүчеләр өчен керү урынына кадәр.

Шул ук вакытта аерымланган территория дигәндә 1 кушымтада күрсәтелгән оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бинага (төзелмәгә, корылмага) янәшә булган, чикләре киртә (ясалма объектлар) белән билгеләнгән территорияне аңларга кирәк.

3. Янәшә территорияләрнең чикләре араны метрларда билгеләү юлы белән түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

1 кушымтада күрсәтелгән оешмаларның аерымланган территориясе булганда, ара аерымланган территориягә килүчеләр өчен керү урыныннан сәүдә объектына, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә, алкоголь продукциясен ваклап сату гамәлгә ашырыла торган стационар объектка килүчеләр өчен керү урынына кадәр иң кыска ара буенча үлчәнә.

Аерымланган территория булмаганда, өстәмә территория оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бинага (төзелмәгә, корылмага) килүчеләр өчен керү урыныннан алып стационар сәүдә объектына яки җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә, объектка килүчеләр керү урынына кадәр билгеләнә.

Стационар сәүдә объектының, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату гамәлгә ашырыла торган объектның яки 1 кушымтада күрсәтелгән оешмалар урнашкан бинаның (төзелмәнең, корылманың) керүчеләр өчен берничә керү урыны булганда, ара һәр керү урыныннан үлчәнә. Янәшә территорияләрнең чикләрен билгеләгәндә янгын сүндерү, биналарга (төзелмәләргә, корылмаларга) запас һәм башка керү юллары исәпкә алынмый.

Сәүдә объектлары, оешмалар бер бинада урнашкан очракта, ара бинаның сәүдә объекты урнашкан өлешенә килүчеләр өчен керү урыныннан бинаның оешма урнашкан өлешенә килүчеләр өчен керү урынына кадәр иң кыска ара буенча үлчәнә.

Янәшә территорияләрнең иң кыска ара буенча размеры тротуарлар яки җәяүлеләр юлы (алар булмаганда – юл кырыйлары, велосипед юллары, машина йөрү өлешләренең кырыйлары буенча), җәяүлеләр кичүләре (җир асты һәм җир өсте) буенча билгеләнә. Җәяүлеләр зонасы машина йөрү өлеше белән кисешкәндә, ара якындагы җәяүлеләр кичүе буенча үлчәнә.

Тротуарлар, җәяүлеләр юллары, җәяүлеләр кичүләре буйлап ара әлеге объектларның уртасыннан (үзәк линиясеннән) үлчәнә. Тротуар дигәндә урамның бер ягында яки кырыйларында урнашкан, машина йөрү өлешеннән югарырак күтәрелгән һәм аннан функциональ яктан аеру өчен бордюр белән чикләнгән таш, агач яки асфальт юлны аңларга кирәк, җәяүлеләр хәрәкәте өчен билгеләнгән һәм машина йөрү өлешенә тоташкан яки аннан газон белән аерылган автомобиль юлын төзекләндерү элементы. Җәяүлеләр кичүе дигәндә махсус билгеләр һәм (яки) тамгалар белән билгеләнгән һәм җәяүлеләр өчен юл аша хәрәкәт итү өчен бүлеп бирелгән юл участогын аңларга кирәк.